КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО СОЦИАЛЬНО-
ЭКОНОМИЧЕСКОМУ
МОНИТОРИНГУ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ
МОНИТОРИНГ
КОМИТЕТЫ

ПРИКАЗ **БОЕРЫК**

10.02.2016 Казан шәһәре **N 3-ос**

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәтенең аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан чит илләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы яисә махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 10 октябрендәге № 506 Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан чит илләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 12 гыйнварындагы № УП-5 Указы нигезендә

б о е р ы к б и р ә м:

1.Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында (алга таба – Комитет) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибе турында кушымта итеп бирелүче нигезләмәне расларга.

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы Комитеттагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга тиеш.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис урынбасары **О.Ю. Семенова**

Татарстан Республикасының
Социаль-икътисадый
мониторинг комитетының 2016
елның «10» февралендә № 3-ос
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибе турындагы нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә белән, әгәр граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларына шушы оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек кермәсә, Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – граждан хезмәткәре) тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләкләүләрен (алга таба – исемнәр, бүләкләүләр) кабул итеп алу тәртибе билгеләнә.

2. Граждан хезмәткәре исемнәр, бүләкләүләр алганда Татарстан Республикасы Комитеты Рәисе (алга таба – Рәис) рөхсәтен алырга тиеш.

3. Исем, бүләкләү алган йә чит дәүләттән, халыкара оешмадан, сәяси партиядән, башка иҗтимагый берләшмәдән, дини берләшмәдән аларны алачагы турында хәбәрнамә алган граждан хезмәткәре, мактаулы яисә махсус исем алуга рөхсәт сорап, Рәис исеменә язылган һәм әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта формасы нигезендә төзелгән үтенечнамәне (алга таба – үтенечнамә) өч эш көне эчендә дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторына тапшыра. Үтенечнамәне карау срогы 10 эш көне тәшкил итә.

4. Исемнән, бүләкләүдән баш тарткан граждан хезмәткәре чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы яисә махсус исемен, бүләкләвен алудан баш тартуы турында Рәис исеменә язылган һәм әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта формасы нигезендә төзелгән хәбәрнамәне (алга таба – хәбәрнамә) өч эш көне эчендә дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторына тапшыра.

5. Рәис исем, бүләкләү алган граждан хезмәткәренең үтенечнамәсен карау нәтиҗәләре буенча карар кабул иткәнче, исемгә, бүләкләүгә документларның төп нөсхәләрен һәм аларга кушып бирелүче документларның төп нөсхәләрен, аларны алганнан соң өч эш көне эчендә, дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторына җаваплы саклауга тапшыра. Бу чакта әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта формасы нигезендә тапшыру-кабул итеп алу акты төзелә.

6. Граждан хезмәткәре хезмәт командировкасы вакытында исем, бүләкләү алганчы алардан баш тарткан очракта, үтенечнамәне тапшыру срогы граждан хезмәткәре хезмәт командировкасыннан кайткан көннән исәпләнә башлый.

7. Граждан хезмәткәре үзенә бәйле булмаган сәбәп аркасында үтенечнамәне яисә хәбәрнамәне, исемгә, бүләкләүгә документларның төп нөсхәләрен һәм аларга кушып бирелүче документларның төп нөсхәләрен әлеге Нигезләмәнең 3 – 5 пунктларында күрсәтелгән срокта тапшыра алмаган очракта, ул үтенечнамәне яисә хәбәрнамәне, исемгә, бүләкләүгә документларның төп нөсхәләрен һәм аларга кушып бирелүче документларның төп нөсхәләрен бу сәбәпне бетергәннән соң килүче эш көне эчендә тапшырырга тиеш.

8. Үтенечнамәне (хәбәрнамәне) теркәү дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы тарафыннан ул теркәү журналына кертелгән көнне әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта формасы нигезендә гамәлгә ашырыла. Теркәлгән үтенечнамәне (хәбәрнамәне) дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы ике эш көне эчендә Рәис каравына җибәрә.

9. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә үтенечнамәне карау нәтиҗәләре буенча Рәис кабул иткән карар турында хәбәр итә һәм аңа дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы мөһере белән таныкланган һәм Рәис резолюциясе куелган үтенечнамә (хәбәрнамә) күчермәсен имза салдырып бирә. Үтенечнамәнең (хәбәрнамәнең) төп нөсхәсе Рәис резолюциясе белән граждан хезмәткәрнең шәхси эшенә беркетеп куела.

10. Рәис граждан хезмәткәренең әлеге Нигезләмәнең 5 нче пунктында күрсәтелгән үтенечнамәсен канәгатьләндергән очракта, дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы 10 эш көне эчендә граждан хезмәткәренә исемгә, бүләкләүгә документларның төп нөсхәләрен һәм аларга кушып бирелүче документларның төп нөсхәләрен тапшыра. Бу чакта әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта формасы нигезендә кабул итеп алу-тапшыру турында акт төзелә.

11. Рәис граждан хезмәткәренең әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән үтенечнамәсен канәгатьләндерүдән баш тарткан очракта, дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы 10 эш көне эчендә исемгә, бүләкләүгә документларның төп нөсхәләрен һәм аларга кушып бирелүче документларның төп нөсхәләрен чит дәүләтнең тиешле органына, халыкара оешмага, сәяси партиягә, башка иҗтимагый берләшмәгә, дини берләшмәгә җибәрә.

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибе турындагы нигезләмәгә

1 нче кушымта

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты Рәисе

_____

_____

_____ дән

(Ф.Ис.Ат ис., биләүче вазыйфасы)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең,
башка иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы яисә махсус исемен,
бүләкләвен кабул итеп алуга рөхсәт сорау турында
үтенечнамә

Миңа _____

(мактаулы яисә махсус исем, бүләкләү атамасы)

кабул итеп алырга рөхсәт итүегезне үтенәм

_____

(нинди казанышлары өчен һәм кем тарафыннан бирелгән, нинди казанышлары өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнгән)

_____

(мактаулы яисә махсус исемгә, бүләкләүгә документлар тапшыру датасы һәм урыны)

Мактаулы яисә махсус исемгә, бүләкләүгә документлар һәм аларга кушып бирелүче документлар (кирәклесенең астына сызарга)

_____

(мактаулы яисә махсус исем, бүләкләү атамасы)

_____

(мактаулы яисә махсус исемгә, бүләкләүгә документлар атамасы)

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторына 20__ елның «___» _____№ ___ кабул итеп алу-тапшыру акты буенча тапшырылган

20 ___ елның « » _____ _____ _____

(имзасы) (имза расшифровкасы)

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибе турындагы нигезләмәгә

2 нче кушымта

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты Рәисе

_____

_____

_____дән

(Ф.Ис.Ат ис., биләүче вазыйфасы)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең,
башка иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы яисә махсус исемен,
бүләкләвен кабул итеп алудан баш тарту турында
хәбәрнамә

_____

(мактаулы яисә махсус исем, бүләкләү атамасы)

алудан баш тартуым турында үзем кабул иткән карар турында хәбәр итәм

_____

(нинди казанышлары өчен һәм кем тарафыннан бирелгән, нинди казанышлары өчен һәм кем тарафыннан бүләкләнгән)

20 __ елның « » _____ _____ _____

(имзасы) (имза расшифровкасы)

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибе турындагы нигезләмәгә

3 нче кушымта

Кабул итеп алу-тапшыру
акты

20__ елның «___» _____ № _____

Без, түбәндә имза салучылар,_____
_____
_____турында акт төзедек
(Ф.Ис.Ат. ис., вазыйфасы)
тапшырды/кабул итеп алды (кирәклесенең астына сызарга), Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы
_____
(Ф.Ис.Ат. ис.) түбәндәгеләрне кабул итеп алды/тапшырды (кирәклесенең астына сызарга):

№ т/н	Атамасы	Саны (данә)	Тасвирламасы
1.			
2.			

Тапшырды _____ Кабул итеп алды _____
(имзасы) (имза расшифровкасы) (имзасы) (имза расшифровкасы)

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләүләрен кабул итеп алу тәртибе турындагы нигезләмәгә

4 нче кушымта

Үтенечнамәләрне
(хәбәрнамәләрне) исәпкә алу
ЖУРНАЛЫ

№	Үтенеч-намә (хәбәрна мә) тапшыр-ган граждан хезмәт-кәре Ф.Ис.Ат. ис.	Үтенеч-намә (хәбәрна-мә) тапшыр-ган граждан хезмәт-кәре вазыйфа-сы	Үтенеч-намә (хәбәр-намә) керү датасы	Бүләк-ләү, исем атамасы	Кабул итеп алу-тапшыру акты реквизитлары (булса)	Үтенеч-намә (хәбәр-намә) кабул итеп алган зат имзасы, Ф.Ис. Ат. ис.	Үтенеч-намә (хәбәр-намә) тапшыр-ган зат имзасы, Ф.Ис. Ат. ис.)	Рәис карары турында мәгълүмат
1								
2								